**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423745, Иске Байсар авылы,
Мәктәп ур., 44а йорт

**СОВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423745, с.Старое Байсарово
ул. Школьная, дом 44а

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«21» ноябрь 2024 ел** **№ 2**

## Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең Чишмәбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең Чишмәбаш авылы : «Иске Байсар авыл җирлегенең Чишмәбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрләрдән тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?
алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);
-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү челтәрләрен тоту, ремонтлау)
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү( һәйкәлне ремонтлау һәм карап тоту).

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 85 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 45 граждан кертелде.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
«Эйе» позициясе өчен 45 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«тыелып калдылар» позиция өчен»  - 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлегенең Чишмәбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныrга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлегенең Чишмәбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрләрдән тыш, 2025 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә, Мәсьәлә буенча карарны танырга,жыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);
-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү челтәрләрен тоту, ремонтлау)
-ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь сатып алу );
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү( һәйкәлне ремонтлау һәм карап тоту).
- торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясендә агачлар кисү,хуҗасыз территорияләр коймаларын ремонтлау;);

3.Әлеге карарны Иске Байсар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aktanysh.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Байсар авыл җирлеге башлыгы                                        Р.М.Кадыйров

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
ОГРН 1021605557456
р-05-11915/08
Совет Старобайсаровского сельского поселения Актанышского муниципального района Республики Татарстан
ИНН 1604000990